# Җөмләдә сызык куелу очраклары

# Беренче очрак:

- Җөмләдә исемнәр яки исем урынында йөри торган сүзләр үзләре генә хәбәр булып килгәндә,ия белән хәбәр арасына:

Хезмәт кешене бар иткән,

Хезмәт-кешегә тормыш

Хезмәт-җирдәге гүзәллек,

Кешегә-һава,сулыш.

# Икенче очрак.

- Ияне аергыч дип тану куркынычы булганда, иядән соң:

  Таш-күперне җимергән.

# Өченче очрак.

- Кискен каршы куюны белдергән теркәгечсез тиңдәш кисәкләр һәм җөмләләр арасында:

Барам,барам-барып җитеп булмый.

# Дүртенче очрак.

- Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан:

Ишек, тәрәзә, идән, түшәм-бары да бик бөтен.

# Бишенче очрак.

- Аныклагач та, аныкланмыш та исем белән белдерелеп, икесенең дә мәгънә күләме бердәй булса сызыклар куела:

Үти алмадым мин әтиемнең васыятен – соңгы теләген.

# Алтынчы очрак.

- Аныклагыч тиңдәш яки бик җәенке булып, аның чиген билгеләү укучыда кыенлык тудырырлык булса аныклагыч ике яктан да сызык белән аерыла:

Урал тауларының көнбатыш һәм көньяк битләрендә - Урал өлкәсендә, Башкортостанда,Казакстанда-яңа нефть чыганаклары табылды.

# Жиденче очрак.

- Текстның укылышына зыян китерердәй кереш җөмләләрне аеру өчен:

  Повар исә - үз музыкасы белән дан казанырга һич тә җыенмаган иде булса кирәк- гармунын кесәсенә тыкты да,балаларга карап,ишарәләр ясады.

# Сигезенче очрак.

- Хәбәре әйтелмәгән, я ким җөмләнең пауза ясала торган урынында:

Мин- аю артыннан,аю-минем арттан.

# Тугызынчы очрак.

- Ике чикне күрсәтә торган сүзләр арасына:

Мәскәү-Берлин поезды.

# Унынчы очрак.

- Туры сөйләм диалог формасында язылганда, һәрбер реплика алдыннннан:

-Кайчан кайттыгыз?

-Кичә.

# Унберенче очрак.

- Туры  сөйләм уртасында һәм аннан соң килгән автор сүзләре янында сызык куела:

-Сез кышны ничек каршылыйсыз?-ди.

-Амбар тулы байлык белән,-дим  мин аңар.

# Уникенче очрак.

- Җөмләләр арасында кискен каршы куюны белдергән “барыбер” сузе алдыннан сызык өтер белән бергә куела:

Кышкы җилләр никадәр генә исмәсеннәр,- барыбыер яз язлыгын итәр.

# Уночении очрак.

- Җөмләнең хәбәре баш килештәге исем,сан, алмашлык, һәм исем –фигыль белән белдерелгәндә:

Мин-балта остасы малае.

# Ундүртенче очрак.

- Җөмләне ике төрле аңлау(синтаксик омоним) ихтималы булса,хәбәре фигыль белән белдерелгән җөмләдә:Теге агач йорт янында тора.1)Теге-агач йорт янында тора.2)Теге агач- йорт янында тора.

# Унбишенче очрак.

- Каршы кую интонациясе булганда:

Аның яшь - җилкенчәк арасында тамчыда абруе калмаган.Бурычка ала- кайтармый.